КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 октябрь г.Казань № 920

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең (алга таба – «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) 2021 елның 1 гыйнварыннан 27 койка-урынга исәпләнгән социаль-тернәкләндерү бүлекчәсен бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге тарафыннан учреждениенең структурасын оптимальләштерү буенча чаралар үткәргәндә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

календарь көннәрдә исәпләнгән 30 көн эчендә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына оператив идарә хокукында «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт

күрсәтү комплекслы үзәге беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең аерым төрләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәр тапшырырга;

«Шәфкать үзәге» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасын оптимальләштерүгә бәйле чыгымнарны, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган акчалар чикләрендә, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча «Шәфкать үзәге» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә чыгымнар өлешендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, календарь көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан бирелгән мөлкәт исемлеге нигезендә, элек «Шәфкать үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт милкен тапшыруны тәэмин итәргә.

4. «Шәфкать үзәге» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасын оптимальләштергәннән соң, бушатылган акчалар «Өлкән буын гражданнарына (Татарстан Республикасы) системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында психоневрологик интернатларда тәрбиячеләрнең штат санын арттыруга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга хезмәт күрсәтүче стационар учреждениеләр өчен аз реабилитация чаралары һәм җиһазлар сатып алуга юнәлдерелә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертергә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң, календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин